**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ НОВОАЛИМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423762, село Новое Алимово, улица Г.Тукая, дом 55.

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА ӘЛЕМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423762, Яңа Әлем авылы . Г.Тукай урамы, 55 йорт.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«14» июль 2021 ел № 12

**Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге Советының 20.06.2016 ел, № 9 карары белән расланган, Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлегенең бюджет процессы нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 15 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «3. Агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә чираттагы финанс елында тиешле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары муниципаль хокукый актлары нигезләмәләре исәпкә алына».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Яңа Әлем авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Актаныш муниципаль районы
Яңа Әлем авыл җирлеге Советы рәисе Д.М.Әнварова